РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава
Сухояшского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Советская, д.32, Азнакаевский район,
с.Большой Сухояш, 423325, тел./факс
(885592)9-80-38
E-mail: Suho.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Сукаеш авыл җирлеге
башлыгы

Советская ур., 32 йорт, Азнакай районы,
Зур Сукаеш авылы, 423325
тел./факс (885592)9-80-38
E-mail: Suho.Azn@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

от «28»октября 2024г. № 6

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлегенең Зур Сукаеш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Уставының 15.1 статьясы белән Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге башлыгы

**Карар чыгара:**

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Зур Сукаеш авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2024 елның 08 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыены билгеләргә.

2.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Зур Сукаеш авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенының уздыру вакыты – 08 ноябрь 2024 ел 12.00 сәг.тән 14.00 сәг.кадәр;

- гражданнар җыенының уздыру урыны – Зур Сукаеш авылы, Совет ур. , 34 йорт, Зур Сукаеш авыл мәдәният йорты залы;

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2024 елның 28 октябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Зур Сукаеш авылы, Совет урамы, 32 йорт

- сайлау хокукына ия булган Зур Сукаеш торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;

- Зур Сукаеш торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда Сукаеш авыл җирлеге Зур Сукаеш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан , гаилә әгъзасы мобилизацияләнгән, хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаиләләрдан тыш, 400 сум күләмендә һэм 2 Төркем инвалидларыннан, 80 яшьтэн өлкәннәрдэн 200 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме: үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Зур Сукаеш авыл җирлегендә урамнарны яктырту өчен лампаларны, яктырткычларны, электр җиһазларын һәм махсус җайланмаларны сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәт күрсәтү;

- Зур Сукаеш авылы чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яшьләр урамында, Бакча урамында, Совет урамында, Мәктәп урамында вак таш салу, юлларны кардан чистарту буенча трактор йөртүче хезмәтләре өчен түләү, торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту буенча чит оешмалар хезмәтләре өчен, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

« РИЗА» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Зур Сукаеш авылы, Совет ур., 30 йорт адресы буенча урнашкан

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга .

6. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Глава
Сухояшского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района
Республики Татарстан: Закирова З.З.